ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 11 2019 г. № 244

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәренең җәмәгать зиратлары эшчәнлеге тәртибен раслау турында» 2014 елның 7 августында кабул ителгән 118 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 22 пункты, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4 пункты, Түбән Кама шәһәре Уставының 6 статьясындагы 1 өлешенең 24 пункты нигезендә карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәренең җәмәгать зиратлары эшчәнлеге тәртибен раслау турында» 2014 елның 7 августындагы 118 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Тәртипнең 2.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Мәрхүмнәрне җирләү зират администраторы ягыннан эшләр башкару технологиясен контрольдә тотып башкарыла. Каберләрне кул белән казырга рөхсәт ителә. Эшләр башкаруның куркынычсызлыгын тәэмин итүче шартлар, кабер өсте корылмаларын, инженерлык челтәрләрен, аллея, юллар, яшел үсентеләрне яки тышкы төзекләндерүнең башка объектларын бозу яки җимерү куркынычы булмаган очракта, грунт торышын һәм һава шартларын исәпкә алып, зират администраторы рөхсәте белән каберне механикалаштырылган ысул белән казырга рөхсәт ителә. Күрсәтелгән мөлкәткә зыян килгән очракта, китерелгән зыян тулы күләмдә кайтарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны ритуаль хезмәтләр бүлеге начальнигы Х.Х.Шәрәповка йөкләргә.

Җитәкче Д.И. Баландин